**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА-
СЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ АЙМАН АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423739, Иске Айман авылы,
Яна ур.,
5а нчы йорт.
Тел.:(85552)3 44 52; факс:3 44 52;
E-mail saym.akt@yandex.ru

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СТАРОАЙМАНОВСКО-
ГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИ-
ПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423739, село Старое Айманово, ул.Новая,дом 5а.
Тел.:(85552)3 44 52; факс:3 44 52;
E-mail saym.akt@yandex.ru

**23.03.2026 ел** **КАРАР** **№10**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 18.12.2023 ел № 19 карарына үзгәрешрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 ел, № 425-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге Советы «Җир салымы турында» 18.12. 2023 ел 19 номерлы карарына (19.12.2023 № 22, 03.04.2024 № 4, 08.11.2024 № 20, 22.10.2025 № 6) кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр әлеге пунктта башкасы каралмаган булса, салымны салым түләүче-оешмалар узган салым чорыннан соң килә торган елның 28 мартыннан да соңга калмыйча түләргә тиеш, салым буенча аванс түләүләре узган хисап чорыннан соң килә торган икенче айның 28 нче числосыннан да соңга калмыйча салым түләүче-оешмалар тарафыннан түләнергә тиеш.»;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«Узган салым (хисап) чорлары өчен салым (салым буенча аванс түләве) суммасын исәпләүгә (яңадан исәпләүгә) китерә торган белешмәләр нигезендә исәпләнгән салым (салым буенча аванс түләве) салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан исәпләнгән салым (салым буенча аванс түләве) турында хәбәр төзелгән айдан соң килә торган айның 28 нче числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш.салым органы тарафыннан тиешле чор өчен салым (салым буенча аванс түләве) суммасына (әлеге статьяда алга табаисәпләнгән салым суммасы турында хәбәр).»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карар 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Актаныш муниципаль районы Иске Айман
авыл җирлеге Советы Рәисе М.Р.Ахметханов